**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

15 декабрь 2025 ел № 08

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Ульяновка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 26 ноябрендәге № 104 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе С.З. Шәмсетдинов

Советның 2025 елның
15 декабрендәге
08 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| № п/п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | Сумма барлыгы, мең сум. |
|---|---|---|
| 1 | Ульяновка, Сосновка һәм Девичья Поляна авылларындагы гидротехник корылмаларны декларация алды тикшерүе | 1500,0 |
| 2 | Гидротехник корылмаларны карап тоту | 115,0 |
| 3 | Су белән тәэмин итү лицензиясен алу өчен документлар әзерләү | 300,0 |
| 4 | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 120,0 |
| 5 | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | 50,0 |
| 6 | Җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 200,0 |
| 7 | Ульяновка, Девичья Поляна авылларында санкцияләнмәгән чүплекләрне рекультивацияләү | 1500,0 |
| 8 | Эчә торган суның сыйфатын СанПиНның билгеләнгән таләпләренә туры китерү | 3000,0 |
| 9 | «Ульяновка авылы мәдәният йорты» МБУда янгын сүндерү җайланмаларын көйләү | 2,4 |
| 10 | Девичья Поляна авылы клубында янгын сүндерү җайланмаларын көйләү | 1,8 |
| 11 | Сосновка авылы клубында янгын сүндерү җайланмаларын көйләү | 1,8 |
| 12 | «Ульяновка мәдәният йорты» МБУга, Девичья Поляна авылы клубына, Сосновка авылы клубына металлодетекторлар (кулныкы) сатып алу | 25,5 |
| 13 | «Ульяновка мәдәният йорты» МБУга, Девичья Поляна авылы клубына, Сосновка авылы клубына тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасы | 30,0 |
| 14 | «Ульяновка мәдәният йорты» МБУга, Девичья Поляна авылы клубына, Сосновка авылы клубына видеокүзәтү камераларын урнаштыру, ремонтлау | 150,5 |
| 15 | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру | 60,0 |
| | Барлыгы: | 7057,0 |